Шәһәр күләмендә математика фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы биремнәре
2025-2026 нчы уку елы
8 нче сыйныф

Эш вакыты – 180 минут
Гомуми балл – 25

1 нче бирем. ***(5 балл)***
$x^2 + y^2 + xy - x - y = 14$ тигезләмәсен натураль саннар кулланып чишегез.

2 нче бирем. ***(5 балл)***

Тигезләмәнең тамырларын табыгыз: (*5 балл)*

$(x^3 + 2x^2 - 15x) / (3 - x) = 0.$

3 нче бирем. ***(5 балл)***

ABC өчпочмагында BAC һәм ABC почмакларының биссектрисалары O ноктасында кисешәләр. AOB почмагы 115°. ACB почмагы ничә градусны тәшкил итә?



4 нче бирем. ***(5 балл)***
1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9 саннары арасыннан берсен 10 данә итеп алыгыз (мәсәлән 6, 6, 6, 6, 6, 6, 6, 6, 6, 6), араларына арифметика алымнарының тамгаларын һәм җәяләр (кирәк булса) куегыз. Нәтиҗәдә 2022 булсын. Башка саннардан ясау да баллар белән хуплана. *(5 балл).*

5 нче бирем. ***(5 балл)***
Ребустагы төрле цифрлар хәрефләр белән алмашынган

БОКС
+
БОКС
СПОРТ

Хәрефләрдә яшеренгән цифрларны табыгыз.